# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Өтәк авылы Өтәшкә авыл җирлегендә халык җыены нәтиҗәләре турында**

2020 елның 10 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта узган җыен беркетмәсе төзелде, сорау буенча:

"Сез 2021 елда үзара салым кертүгә Яшел Үзән муниципаль районының Өтәк авылы Өтәшкә авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- яктырткычлар урнаштыру, урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту;
- Тынычлык урамындагы элеккеге мәктәп бакчасы урынында паркны төзекләндерү;
- смета документларын әзерләү һәм төзелеш контролен тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 48 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 38 кеше катнашкан, гражданнар җыенында катнашучылар 79,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 38 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Өтәк авылы Өтәшкә авыл җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – чын.
2. 2021 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Өтәк авылы Өтәшкә

авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- яктырткычлар урнаштыру, урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту;
- Тынычлык урамындагы элеккеге мәктәп бакчасы урынында паркны төзекләндерү;
- смета документларын әзерләү һәм төзелеш контролен тормышка ашыру.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче А.А. Клопов